ГЛАВА БАЛТАСИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШЛЫГЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«4» апреля 2020 г. № _77__

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау хакында**

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Татарстан Республикасы Президентының Указы, «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы Россия ГХМ (МЧС) боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын һәрьяклап тәэмин итүне оештыру максатларында **Балтач муниципаль районы башлыгы карар бирә:**

1.Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне расларга.

2.Балтач муниципаль районы оешмалары һәм учреждениеләре җитәкчеләренә, аларның оештыру-хокукый формаларына бәйсез рәвештә, гамәлдәге законнар нигезендә оешмада гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмә эшләргә һәм расларга тәкъдим итәргә.

3.Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4.Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Балтач муниципаль
районы башлыгы Р. Р. Нотфуллин

Балтач муниципаль
районы башлыгының 2020 елның
«____» __________ ______
номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмә**

1.Әлеге Нигезләмә «Граждан оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Татарстан Республикасы Президентының Указы, «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау турында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла – казалардан килгән зыяннарны бетерү буенча Россия Федерациясе министрлыгының боерыгы нигезендә эшләнде һәм гражданнар оборонасын алып баруга әзерлекне һәм алып баруны оештыру һәм төп юнәлешләрен, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында (алга таба - Балтач муниципаль районы) гражданнар оборонасы буенча төп чараларны билгели.

2. Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасы чаралары Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек һәм алып бару кысаларында оештырыла.

3.Гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби низаглар вакытында яки бу низаглар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә, куркынычлардан яклауга әзерлек чараларын вакытында үтәүдән гыйбарәт һәм Балтач муниципаль районының гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча төп чараларны күздә тоткан еллык план (алга таба - Балтач муниципаль районының төп чаралары планы) нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Балтач муниципаль районының бер елга төп чаралар планы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан эшләнә һәм граждан оборонасы бурычларын һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бурычларын махсус хәл итәргә вәкаләтле орган, Татарстан Республикасы буенча - Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла – казалардан килгән зыяннарны бетерү буенча Россия Федерациясе министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе (алга таба - Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе) белән килештерелә.

Гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек һәм алып бару буенча төп чараларны планлаштыру, хәрби низагларда яисә шушы низаглар нәтиҗәсендә,

шулай ук мөмкин булган террорчылык актлары һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә заманча җиңелү чараларын куллану нәтиҗәсендә Балтач муниципаль районы территориясендә килеп чыгарга мөмкин булган хәлне һәрьяклап бәяләүне исәпкә алып башкарыла.

5. Муниципаль дәрәҗәдә гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек муниципаль берәмлектә гражданлык оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмә белән билгеләнә һәм хәрби низаглар вакытында яки бу низаглар нәтиҗәсендә барлыкка килә торган куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә, Балтач муниципаль районы территориясендә халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне яклау чараларын планлаштырудан гыйбарәт.

Муниципаль дәрәҗәдә гражданнар оборонасын алып бару Балтач муниципаль районының Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы нигезендә гамәлгә ашырыла һәм хәрби низагларда яки бу низаглар нәтиҗәсендә килеп чыккан куркынычлардан, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта, Балтач муниципаль районы территориясендә халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау буенча чараларны үтәүдән гыйбарәт.

6.Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы сугыш вакытында гражданнар оборонасын үткәрү һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын үтәүнең күләмен, оештыруны, тәэмин итү тәртибен, ысулларын һәм вакытларын билгели.

Гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чараларны тыныч вакытта үтәү Табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чаралар планы нигезендә гамәлгә ашырыла.

6.1.Балтач муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чараларны тәэмин итү идарә органнары, гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы көчләре һәм чаралары белән башкарыла.

Балтач район башкарма комитеты Балтач муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итүче оешмалар исемлеген билгели.

7.Балтач район башкарма комитеты гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатларында, гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләр нигезендә көчләр, акчалар, гражданнар оборонасы объектлары, матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запаслары булдыра һәм аларны тәэмин итеп тора, гражданнар оборонасы чараларын планлаштыра һәм гамәлгә ашыра.

8.Балтач район башкарма комитеты карары буенча коткару хезмәтләре (медицина, инженерлык, коммуналь-техник, янгынга каршы, җәмәгать тәртибен саклау, хайваннар һәм үсемлекләрне яклау, хәбәр итү һәм элемтә, транспорт белән тәэмин итү, ягулык-майлау материаллары, юл, энергетика, сәүдә һәм туклану) барлыкка килергә мөмкин, аларны оештыру һәм аларның

эшчәнлек тәртибе коткару хезмәтләре турындагы тиешле нигезләмәләрдә аларны булдыручы органнар һәм оешмалар тарафыннан билгеләнә.

Коткару хезмәте составына гражданлык оборонасы буенча чаралар үткәрү, авария-коткару формированиеләре гамәлләрен һәрьяклап тәэмин итү һәм хәрби низаглар вакытында яисә шушы низаглар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен билгеләнгән идарә органнары, көчләр һәм граждannar оборонасы чаралары керә.

Коткару хезмәтләренең төре һәм саны граждannar оборонасы һәм халыкны яклау планнары нигезендә башкарыла торган бурычлар күләмен һәм характерын исәпләү нигезендә билгеләнә.

Балтач муниципаль районының коткару хезмәте турындагы нигезләмә коткару хезмәте җитәкчесе тарафыннан эшләнә, Татарстан Республикасының тиешле коткару хезмәте җитәкчесе белән килештерелә һәм Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

Балтач муниципаль районында граждannar оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыру һәм аларның әзерлеген тәэмин итү буенча методик җитәкчелекне, шулай ук әлеге өлкәдә контрольне Граждannar оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла – казалардан килгән зыяннарны бетерү буенча Россия Федерациясе министрлыгы (алга таба - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы) һәм Россия ГХМның Татарстан Республикасы буенча баш идарәсе гамәлгә ашыра.

9.Балтач район башкарма комитеты тарафыннан эвакуация чараларын планлаштыру, әзерләү һәм уздыру өчен алдан ук, тыныч вакытта, эвакуация комиссиясе төзелә. Эвакуация комиссиясен Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары җитәкли. Эвакуация комиссиясе эшчәнлеге Балтач муниципаль районының граждannar оборонасы җитәкчесе тарафыннан расланган эвакуация комиссиясе турында Нигезләмә белән регламентлана.

10.Тыныч вакытта граждannar оборонасы көчләре табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чараларда катнашу өчен җәлеп ителергә мөмкин.

Балтач муниципаль районы граждannar оборонасы җитәкчесе үзе төзегән граждannar оборонасы көчләренә карата тыныч вакытта граждannar оборонасы көчләрен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча чараларда катнашу өчен җәлеп итү турында карарны кабул итә.

11.Балтач муниципаль районы территориясендә граждannar оборонасы белән җитәкчелек итүне Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе башкара.

Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе граждannar оборонасы һәм халыкны яклау чараларын оештыру һәм үткәрү өчен шәхси җавап тота.

12.Балтач муниципаль районында граждannar оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыручы орган булып, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә төзелә торган, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча граждannar оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле структур бүлекчәсе тора.

Балтач район башкарма комитеты гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле структур бүлекчәсен комплектлаштыра, аларның функциональ вазыйфаларын һәм штат расписаниесен эшли һәм раслый.

Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле структур бүлекчә җитәкчесе турыдан-туры Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә буйсына.

13.Гражданнар оборонасы буенча гамәлләрне оешкан һәм планлы рәвештә гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шул исәптән тыныч вакытта һәм сугыш вакытында фаразланган һәм килеп чыккан куркынычлар турында халыкка үз вакытында хәбәр итү максатларында Балтач муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм аны алмашу оештырыла.

Балтач муниципаль районы территориясендә мәгълүмат җыю һәм алмашу «Балтач муниципаль районының гражданнарны яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Балтач район башкарма комитеты мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тапшыра.

14.Муниципаль дәрәҗәдә гражданнар оборонасы чаралары федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы җитәкчесенең күрсәтмә документлары, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

15.Балтач район башкарма комитеты, гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатыннан, түбәндәге төп чараларны планлаштыра һәм тормышка ашыра:

15.1. Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны әзерләү буенча:

Балтач муниципаль районы үзенчәлекләрен исәпкә алып һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган үрнәк программалар нигезендә эшләүче халыкны, вазыйфаи затларны һәм гражданнар оборонасы хезмәткәрләрен, Балтач муниципаль районы оешмаларының һәм хезмәтләренең шәхси составын әзерләүнең үрнәк программаларын эшләү;

Балтач муниципаль районы халкын хәрби низаглар вакытында яисә шушы низаглар нәтиҗәсендә барлыкка килә торган хәвеф-хәтәрләрдән, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә саклану ысулларын әзерләү һәм оештыру;

Балтач муниципаль районы формированиеләренең һәм хезмәтләренең шәхси составын әзерләү;

гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм күнекмәләр үткәрү;

оештыру-методик җитәкчелек һәм Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан формированиеләрнең һәм хезмәтләрнең хезмәткәрләрен, шәхси составын әзерләүне контрольдә тоту;

гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктларын булдыру, җиһазлау һәм аларның эшчәнлеген оештыру, шулай ук тиешле лицензиясе булган өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрендә Балтач муниципаль районы вазыйфаи затларының һәм гражданнар оборонасы хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;

гражданнар оборонасы өлкәсендә белемнәрне пропагандалау.

15.2. Хәрби низаглар вакытында яки бу низаглар нәтиҗәсендә барлыкка килә торган куркынычлар турында халыкка хәбәр итү буенча, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килгәндә:

халыкка үзәкләштерелгән хәбәр итү системасын даими әзерлектә тоту, аны реконструкцияләү һәм модернизацияләү;

кешеләр күпләп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын урнаштыру;

Россия Федерациясе бердәм электр элемтәсе челтәре, радио-, үткәргеч һәм телевизион тапшырулар чаралары һәм башка мәгълүмат тапшыруның техник чараларыннан комплекслы файдалану;

Гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүматны җыю һәм алмашу.

15.3. Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне куркынычсыз районнарга эвакуацияләү буенча:

халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне мөмкин булган хәвеф-хәтәр зоналарыннан куркынычсыз (имин) районнарга эвакуацияләүне планлаштыруны, әзерләүне һәм уздыруны оештыру, шулай ук сугыш вакытында үз эшчәнлеген дәвам итүче оешмалар хезмәткәрләрен һәм мөмкин булган хәвеф-хәтәр зоналарында гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәүне тәэмин итүче оешмалар хезмәткәрләрен таратып урнаштыру;

эвакуацияләнергә тиешле халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне урнаштыру өчен куркынычсыз районнар әзерләү;

эвакуация органнарын булдыру  һәм эшчәнлеген оештыру, шулай ук аларның шәхси составын әзерләү.

15.4. Халыкка шәхси һәм коллектив саклану чараларын бирү буенча:

гражданнар оборонасының саклагыч корылмаларына һәм аларның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү системаларын төзү, саклау, билгеләнеше буенча куллануга даими әзерлек хәлендә тоту һәм техник хезмәт күрсәтү

тыныч вакытта һәм гражданнар оборонасын тыныч вакыттан сугыш вакытына күчергәндә,  тирәнәйтелгән биналарны һәм җир асты киңлекләренең башка корылмаларын халыкны качырып тору өчен җайлаштыру;

сугыш вакытында гражданнар оборонасының җитмәгән саклагыч корылмаларын төзүне планлаштыру һәм оештыру;

гражданнар оборонасының саклау корылмаларында, тирәнәйтелгән биналарда һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларында халыкны качырып торуны тәэмин итү;

халыкны шәхси саклау чараларын туплау, саклау, яңарту һәм билгеләнеше буенча куллану;

- билгеләнгән вакытта халыкка шәхси саклану чараларын һәм коллектив саклау чараларын  бирүне тәэмин итү;

15.5. Яктылык һәм башка төр маскировка буенча:

маскировкаланырга тиешле объектлар исемлеген билгеләү;

билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы төркемнәренә кертелгән территорияләрне комплекслы маскировкалау планнарын эшләү;

- яктылык маскировкасы һәм башка төр маскировка буенча чаралар үткәрү өчен кирәкле матди-техник чаралар запасларын булдыру һәм билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту;

15.6. Хәрби низагларда яки әлеге низаглар нәтиҗәсендә халык өчен куркынычлар барлыкка килгән очракта, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү буенча:

гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтүнең һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасын булдыру, җиһазландыру һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;

авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне һәрьяклап тәэмин итү өчен матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту;

15.7. Хәрби низагларда яисә бу низаглар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдә зыян күргән халыкның яшәешен беренче чиратта тәэмин итү:

халык яшәешен беренче чиратта тәэмин итүнең төп төрләрен планлаштыру һәм оештыру;

матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек хәлендә тоту;

халыкны азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән нормалаштырылган тәэмин итү;

халыкка коммуналь-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү;

зыян күргән халык арасында санитария-гигиена һәм эпидемиягә каршы чаралар үткәрү;

дәвалау-эвакуация чараларын үткәрү;

куркынычсыз районда кирәкле дәвалау базасын җәелдерү, аны энергия һәм су белән тәэмин итүне оештыру;

халыкка беренче ярдәм күрсәтү;

тораксыз калган халык санын билгеләү;

сакланып калган торак фондын инвентаризацияләү һәм зыян күргән торак фондының торышын бәяләү, аны зыян күргән халыкны урнаштыру өчен файдалану мөмкинлеген билгеләү;

зыян күргән халыкны ял йортларында, пансионатларда һәм башка сәламәтләндерү учреждениеләрдә, вакытлыча торакларда (җыелма йортларда, палаткаларда, землянкаларда) урнаштыру, шулай ук аны сакланып калган торак фонды мәйданына күчерү;

халыкка мәгълүмати-психологик ярдәм күрсәтү.

15.8. Хәрби низагларда яки бу низаглар нәтиҗәсендә барлыкка килгән янгыннарга каршы көрәш:

муниципаль янгын сагы булдыру һәм аның эшчәнлеген оештыру, аның гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерлеген һәм янгыннан саклауның башка төрләре белән үзара бәйләнешен оештыру;

авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү районнарында һәм билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категориясенә кертелгән оешмаларда сугыш вакытында янгыннарны сүндерүне оештыру;

янгыннарны сүндерү өчен химик реагентлар запасларын алдан ук булдыру;

15.9. Радиоактив, химик, биологик һәм башка зарарлануга (пычратуга) дучар булган районнарны ачыклау һәм билгеләү буенча:

Гражданнар оборонасын күзәтү һәм лаборатор контроль һәм халыкны яклау челтәрләрен - Балтач муниципаль районы территориясендәге радиацион, химик, биологик хәлләрне күзәтү һәм тикшереп тору функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органнарын, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм оешмаларның гамәлдәге махсуслаштырылган учреждениеләрен, бүлекчәләрен һәм хезмәтләрен булдыру һәм әзерлеген тәэмин итү;

радиоактив пычрануга дучар булган территорияләрдә радиациядән саклау режимнарын кертү;

15.10.Халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү буенча:

дезактивация, дегазация һәм дезинфекция матдәләре һәм эремәләре запасларын алдан ук булдыру;

халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү өчен көчләр булдыру һәм җиһазландыру, аларны гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү буенча чаралар үткәрүне оештыру;

15.11.Хәрби низагларда яисә бу низаглар нәтиҗәсендә зыян күргән районнарда, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр һәм террорчылык акцияләре нәтиҗәсендә зыян күргән районнарда тәртип булдыру һәм саклау буенча:

җәмәгать тәртибен саклау көчләрен булдыру һәм җиһазландыру, аларны гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

җәмәгать тәртибен булдыру һәм саклау, гражданнар оборонасы көчләренең хәрәкәт маршрутларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү һәм халыкны эвакуацияләү;

авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләр үткәрү өчен гражданнар оборонасы көчләренең тоткарлыксыз хәрәкәтен тәэмин итү;

зарарлану урыннарында пропуск режимын гамәлгә ашыру һәм җәмәгать тәртибен саклау;

эчке эшләр органнары тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле объектларны, шартнамәләр буенча юридик һәм физик затлар мөлкәтен саклауны көчәйтү, караучысыз калган мөлкәтне саклау буенча чаралар күрү;

15.12.Хәрби вакытта кирәкле коммуналь хезмәтләрнең эшләвен тиз арада торгызу мәсьәләләре буенча:

коммуналь хезмәтләрнең сугыш вакыты шартларында эшләргә әзерлеген тәэмин итү һәм аларның гамәлләрен планлаштыру;

зыян килгән газ, энергия, су белән тәэмин итү, ташландык суларны агызу һәм канализация системаларын ремонтлау өчен җиһазлар һәм запас частьләр запасларын булдыру;

суны чистарту, төчеләндерү һәм транспортлау өчен мобиль чаралар резервын булдыру һәм әзерләү;

су үткәрү станцияләрендә реагентлар, реактивлар, консервантлар һәм дезинфекция чараларының кирәкле запасларын булдыру;

халыкны коммуналь тәэмин итүне оештыру өчен резервуарлар һәм сыешлыклар, җыела-сүтелә торган торба үткәргечләр, мобиль резерв һәм автоном энергия чыганаклары, җайланмалар һәм техник чаралар запасларын булдыру;

15.13.Сугыш вакытында мәетләрне тиз арада күмү буенча:

алдан ук, тыныч вакытта, күмәргә мөмкин булган урыннарны билгеләү;

мәетләрне күмү чараларын тәэмин итү өчен, шул исәптән махсуслаштырылган ритуаль оешмалар базасында, гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыру, әзерләү һәм әзерлеген тәэмин итү;

һәлак булган кешеләрнең мәетләрен (җәсәдләрен) җирләү (күмү) урыннарын җиһазландыру;

мәетләрне эзләү, аларның табылу урыннарын теркәү, аларны алу һәм беренчел эшкәртү, үлүчеләрне тану һәм документлаштыру, үлгән кешеләрне күчерү һәм күмү эшләрен оештыру;

санитар-эпидемиологик күзәтчелекне оештыру.

15.14.Хәрби низаглар вакытында яисә әлеге низаглар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә халыкның исән калуы өчен кирәкле оешмаларның эшләвенең тотрыклылыгын тәэмин итү буенча:

икътисад эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча комиссия төзү, тыныч вакытта һәм сугыш вакытында аның эшен оештыру;

төзелеш нормалары һәм гражданнар оборонасының инженерлык-техник чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләре таләпләренә туры китереп, икътисад һәм инфраструктура объектларын, шулай ук җитештерү чараларын рациональ урнаштыру;

куркыныч янаган чорда комплекслы маскировкалау буенча чаралар планлаштыру һәм уздыру;

энергия һәм су белән тәэмин итү системаларының һәм чыганакларының эшчәнлеге ышанычлылыгын күтәрүгә юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм үткәрү;

тыныч вакытта һәм сугыш вакытында гражданнар оборонасының инженерлык-техник чараларын, шул исәптән төзелеш проектларында, эшләү һәм гамәлгә ашыру;

сугыш вакытында эшен дәвам итә торган икътисад объектларында авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү;

җитештерү процессын торгызу өчен кирәкле матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын алдан ук булдыру;

документларның иминият фондын булдыру;

аларга заманча зарарландыру чаралары тәэсир иткәндә, җитештерү фондларын саклау нәтиҗәлелеген арттыру;

15.15.Гражданнар оборонасы көчләренең һәм чараларының даими әзерлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча:

гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм заманча техника һәм җиһазлар белән тәэмин итү;

гражданнар оборонасы көчләрен гамәлләргә әзерләү, гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм күнекмәләр үткәрү;

гражданнар оборонасы көчләренең гамәлләрен планлаштыру;

гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү һәм үзара хезмәттәшлек тәртибен билгеләү, шулай ук аларның гамәлләрен һәрьяклап тәэмин итү.

16.Балтач муниципаль районының гражданнар оборонасы чараларын финанслау гамәлдәге законнар нигезендә башкарыла.